# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Куллanучылар хокукларын яклау турында Татарстан Республикасының аерым закон актларының үз көчләрен югалтуларын тану хакында**

**1 статья.** Түбәндәгеләрнең үз көчләрен югалтуларын таныrга:

«Кулланучылар хокукларын яклау турында» Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 7);

«Кулланучылар хокукларын яклау турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1997 елның 16 апрелендәге 1134 номерлы карары (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 7).

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**3 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 27 июне
№ 902